ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
V чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
V созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**22.09.2025 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№01-06**

**Актаныш муниципаль районы Советының ««Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен, контрольно-хисап органы рәисен, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын командировкалау тәртибе һәм шартлары турында» 2023 елның 15 декабрендәге 33-03 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Җирле үзидарә органнарында хезмәткәрләрне командировкага җибәрүне камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының ««Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен, контрольно-хисап органы рәисен, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын командировкалау тәртибе һәм шартлары турында» 2023 елның 15 декабрендәге 33-03 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче бүлекнең 3.3 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Командировкага җибәрелгән хезмәткәрләргә торак урынны броньлау һәм наемга алу чыгымнары (аларга түләүсез торак урын бирелгән очраклардан тыш) тиешле документлар белән расланган факттагы чыгымнар буенча «эконом» яисә «стандарт» классы номеры бәясеннән артмаган күләмдә түләнә.

1.2. 3 нче бүлекнең 3.3 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Советы рәисе Л.Р. Зарипов